РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ РУНГИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЫРЫҢГЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

«25» сентябрь 2017 ел № 1-35

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының
Ырыңгы авыл җирлеге Советының 2013 елның
22 февралендәге 1-35 номерлы карары (2016 елның
28 июнендәге 1-13 номерлы карар редакциясендә) белән
расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Ырыңгы авыл җирлегенең Җирдән
файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Ырыңгы авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатында «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2007 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә Буа муниципаль районының Ырыңгы авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

I. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Ырыңгы авыл җирлеге Советының 2013 елның 22 февралендәге 1-35 номерлы карары (2016 елның 28 июнендәге 1-13 номерлы карар редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Ырыңгы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертергә:

1. 8 статья:
2 өлештә «… Ырыңгы авыл җирлеге җирләреннән файдалануга җир контролен гамәлгә ашыра;…» сүзләрен төшереп калдырырга;

II. Әлеге карар имзалангач законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://buinsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарылырга тиеш.

III. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам

Буа муниципаль районының Ырыңгы
авыл җирлеге башлыгы Р.И. Гордеев